| | | |
|---|---|---|
| **«Хуплыйм»** | **«Раслыйм»** | **«Раслыйм»** |
| **«Сәләт» проектлары житәкчесе** | **«Сәләт» ТРЯФ Генераль директоры** | **«Сәләт» яшьләр үзәге директоры** |
| **_________Әдип Әлмир** | **_______Э.Р. Насибуллина** | **________А.Т. Габдрахманова** |
| **«9» сентябрь 2024 ел** | **«9» сентябрь 2024 ел** | **«9» сентябрь 2024 ел** |

**«Әйдаманнар ярышы - 2024»**

**Республикакүләм әйдаманлык осталыгы конкурсы**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Ярышны оештыручылар

1.1. «Әйдаманнар ярышы - 2024» Республикакүләм әйдаманлык осталыгы конкурсы (алга таба – Ярыш) Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы «Сәләт» региональ фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге һәм «Сәләт» Клубы тарафыннан оештырыла.

## 2. Гомум нигезләмәләр

2.1. Ярыш Сәләтнең җәйге аланнарында катнашкан әйдаманнарның эшчәнлегенә нәтиҗә ясау буларак ел саен үткәрелә.

2.2. Түбәндәге мәгълүмат Оештыручылар тарафыннан билгеләнә, Әдип Әлмир тарафыннан хуплана:

- ярышның нигезләмәсе;
- ярыш үткәрелү урыны һәм вакыты;
- ярышта катнашучылар исемлеге;
- казыйлар исемлеге;
- җиңүчеләрне бүләкләү фонды;
- ярышны үткәрү программасы.

## 3. Ярышның максаты һәм бурычлары

3.1 Ярышның максаты – сәләтле әйдаманнарны ачыклау, аларның потенциалын ачарга һәм үстерергә булышлык күрсәтү.

3.2 Ярыш үз алдына түбәндәге бурычларны куя һәм тормышка ашыра:

- әйдаманнарның профессиональ осталыгын арттыру өчен шартлар тудыру;
- балаларның ялын оештыруда инновацияләр, яңа технологияләр һәм юнәлешләр эзләү;
- әйдаманнарның нәтиҗәле эшчәнлек тәҗрибәсен үзара алмашу һәм тарату өчен шартлар тудыру;
- яшьләрнең иҗади һәм профессиональ мөмкинлекләрен тормышка ашыруда ярдәм итү.

## 4. Ярышны үткәрү тәртибе

4.1. Ярыш ике этапта үткәрелә:

- 1-нче этап – читтән торып катнашу этабы, катнашучыларны портфолио нигезендә сайлап алу (9 сентябрь – 9 октябрь, 2024 ел);

- 2-нче этап – шәхсән катнашу этабы, ярыш программасы (15 октябрь – 19 октябрь, 2024 ел)

4.2. Ярышта катнашырга теләк белдергән әйдаман 6 нчы ноябрьгә кадәр selet.biz сайтында гариза тутырырга тиеш.

4.3. Читтән торып портфолио нигезендә сайлап алу этабы нәтиҗәсендә, катнашучылар 15 октябрьдән 19 октябрьгә кадәр үткәрелүче ярыш программасында катнашырга чакырылалар.

4.4. Ярыш программасы нәтиҗәсендә җиңүчеләр һәм лауреатлар билгеләнә.

4.5. Оештыру комитеты, көтелмәгән шартлар барлыкка килү очрагында, ярышның үткәрелү вакытын үзгәртергә хокуклы.

4.6. Оештыру комитеты гаризалар кабул итү вакытын озайтырга һәм Ярышны үткәрелмәгән дип игълан итәргә хокуклы.

## 5. Ярышның казыйлар шурасы

5.1. Ярышның казыйлар исемлеге Татарстан Республикасының танылган шәхесләре, «Сәләт» проектлары җитәкчеләре һәм җәйге аланнарда башҗитәк вазыйфасын башкарган, әлеге Ярышта үзләре катнашкан шәхесләрне кертеп оештыру комитеты тарафыннан төзелә һәм Әдип Әлмир тарафыннан хуплана.

5.2. Казыйлар җиңүчеләрне Ярыш программасы нәтиҗәсендә билгели.

5.3. Казыйлар карары үзгәртелми һәм шикаятьләр каралмый.

## 6. Ярышта катнашучылар

6.1Ярышта югары уку йортларында яисә урта махсус белем бирү йортларында укучы, 17 яше тулган Сәләтнең җәйге аланнарында һәм уку-укыту проектларында активлык күрсәткән балалар һәм әйдаманнар катнаша ала.

6.2. «Премьер-лига»

6.2.1. «Премьер-лига» кысаларында Республикакүләм «Әйдаманнар мәктәбе» аша узган, түбәндәге катнашучылар булырга мөмкин:

- ким дигәндә 3 мәртәбә Халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында әйдаман булган;
- ким дигәндә 1 мәртәбә Сәләтнең җәйге профильле аланында әйдаман булган;
- халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында 3 тапкырдан артык башҗитәк булмаган;
- җәй дәвамында Сәләтнең җәйге профильле аланында яки Халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында әйдаман булучылар.

6.3. «Беренче лига»

6.3.1. «Беренче лига» катнашучысы булырга мөмкин:

- республикакүләм «Әйдаманнар мәктәбе» аша узмаган студентлар, булачак әйдаманнар;
- республикакүләм «Әйдаманнар мәктәбе» аша узган, халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында күп дигәндә 1-2 мәртәбә әйдаман булган әйдаманнар.

6.4. Катнашучылар әлеге нигезләмәнең барлык шартларын үтәргә тиеш.

## 7. Ярыш программасы

7.1. «Мин – сәләтле әйдаман»

7.1.1. Әлеге конкурс катнашучының «Мин – сәләтле әйдаман» темасына юнәлтелгән чыгышыннан гыйбарәт. Чыгыш түбәндәге сорауларны чагылдырырга тиеш:

- катнашучы турында мәгълүмат (тулы исеме, яше, уку йорты һ.б.);
- Сәләт проектларында катнашу;
- төрле дәрәҗәдәге уңышлары;
- кызыксынулары;
- ярыш темасына кагылган башка мәгълүмат.

7.1.2. Катнашучы өчен мәҗбүри шартлар:

- чыгыш 3 минуттан артмаган булырга тиеш;
- электрон форматта булган презентация (Power Point, Prezi һ.б.)

7.1.3. Регламент:

- һәр катнашучыга чыгыш өчен 3 минут вакыт бирелә. Вакыт чыгу белән чыгыш туктатыла. Казыйлардан өстәмә сораулар булмаячак.

7.2. «Шәмчек»ләр

7.2.1. Һәрбер катнашучы «Шәмчек» программасын әзерли. Сайлап алу туры өчен «Шәмчек» темасын катнашучы мөстәкыйль рәвештә сайлый. Финал этабы өчен темаларны оештыру комитеты тәкъдим итәчәк.

7.2.2. «Шәмчек» уздыру тәртибе:

- кереш өлеш: «Шәмчек»нең максаты һәм бурычлары, аның темасы;
- төп өлеш: аралашу;
- нәтиҗә ясау өлеше: «Шәмчек» катнашучылары үзләре өчен нинди файдалы мәгълүмат алалар;
- тәмамлау өлеше: берләшү мизгеле.

7.2.3. Регламент:

- I тур. Һәрбер катнашучы кечкенә төркемнәрдә үзләренең шәмчекләрен уздыра. Шәмчек уздыру өчен 15 минут вакыт бирелә. Вакыт бетү белән,

катнашучының чыгышы тәмамлана. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты үзгәрергә мөмкин.

- II тур. 1-нче тур нәтиҗәләре буенча һәр лигадан 5 иң яхшы катнашучы үзләренең шәмчекләрен уздыралар. Шәмчек уздыру вакыты – 20 минут. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты һәм катнашучылар саны үзгәрергә мөмкин.

7.2.4. Бәяләү критерийлары:

- теманы сайлау, аны аңлата алу; теманың күләме һәм актуальлеге;

- авторлык күләме, креативлык, яңалык;

- шәмчекнең дөрес структурасы булуы;

- шәмчек вакытындагы атмосфера;

- алып бару осталыгы;

7.3. «Сәләтле 60 секунд»

7.3.1. Катнашучы үзенең кабатланмас сәләтен күрсәтергә тиеш. Чыгышлар өчен билгеле бер жанр юк.

7.3.2. Регламент:

- һәр катнашучыга чыгыш өчен 60 секунд вакыт бирелә. Вакыт чыгу белән чыгыш туктатыла. Казыйлардан өстәмә сораулар булмаячак.

7.4. Беренче лига өчен «Төркем эчендә уен» конкурсы

7.4.1. Катнашучы төркем белән үткәреп була торган уеннар тупларга тиеш.

7.4.2. Регламент:

- катнашучыга уенны уйнар өчен билгеле бер очрак бирелә. Вакыт регламенты - 3 минут. Вакыт бетү белән, катнашучының чыгышы тәмамлана. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты үзгәрергә мөмкин. Авторлы уен булуы мәҗбүри шарт түгел.

7.5. Конкурсның барлык этаплары татар телендә генә уза. Конкурсның әлеге пункты үтәлмәгәндә катнашучының чыгышы өчен тискәре баллар куела. Татар телендә сөйләм 3 дәрәҗәдә билгеләнә: чыгыш саф татар телендә; чыгышта башка телдән сүзләр кулланылу һәм кайбер җөмлә төзелешендә хаталар булу

(«калька»); чыгышта башка телдән сүзләрне күпләп куллану һәм җөмлә төзелешенең күп очракта дөрес булмавы (калька).

7.6. Ярышның финалына узган катнашучылар өчен программа финалны үткәрү көнендә хәбәр ителә.

7.7. Оештыру комитеты Ярыш программасына үзгәрешләр кертергә хокуклы.

## 8. Оештыручыларның контаклары.

8.1. Ярышның оештыру комитеты Сәләт йортында (Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт) урнашкан. Элемтәләр өчен телефон: 8 (843) 292-16-00. Эш вакыты: 09:00-18:00, 3-нче бүлмә.

## 9. Конкурста катнашучыларның шәхси белешмәләрен эшкәртү һәм яклау

Оештыручыларга бирелә торган мәгълүмат шәхси мәгълүматларга карый һәм Россия Федерациясе кануннары нигезендә саклана.

Республикакүләм Конкурста катнашып, катнашучы Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль кануны нигезендә үзенең Конкурста катнашуын тәэмин итү, оештыру турында мәгълүмат җиткерү һәм шундый ук чараларда катнашу максатында үзенең шәхси мәгълүматларын автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган эшкәртүгә ризалыгын бирә, шул исәптән: фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, телефон номеры, электрон почта адресы, эшләү/уку урыны, ил, төбәк, шәһәр. Күрсәтелгән шәхси мәгълүматлар бары тик Оештыручылар тарафыннан гына кулланылачак һәм әлеге Конкурска бәйле рәвештә бернинди өченче затларга да бирелмәячәк.

Конкурста катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәрткәндә оештыручылар Россия Федерациясенең 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль канун белән җитәкчелек итә. Оештыручылар шәхси мәгълүматны саклау өчен кирәкле, җитәрлек дәрәҗәдә төрле оештыру һәм техник чаралар күрә.

Тиешле язма документны Оештыручы адресына хат юллау ысулы яисә Оештыручыларга шәхсән тапшыру юлы белән шәхси мәгълүматларны эшкәртү процессы туктатылырга мөмкин.